ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

**23.09.2024** **Чистай шәһәре** **№ 417**

Вазыйфаи затларга административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзү вәкаләтләрен бирү хакында

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы (2024 елның 26 июленә редакциядә), "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында" 2010 елның 8 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының "Чистай муниципаль районында "Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында" 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында" 2015 елның 10 августындагы 455 номерлы карары нигезендә. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче баш һәм әйдәп баручы белгечләренә кушымта нигезендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен кушымта нигезендә бирергә.
2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчече Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына
кушымта
____________ 2024 ел №____________

**ТР АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР КОДЕКСЫНДА КАРАЛГАН АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР СОСТАВЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

| ТР КоАП статьялары | Административ хокук бозу составы |
|---|---|
| ТР КоАП 2.1 статьясы | Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын, башка дәүләт органын, җирле үзидарә органын, предприятиене, учреждениене, башка оешманы үз исеме һәм мәгълүматны чыгарырга тиешле башка белешмәләр күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата) |
| ТР КоАП 2.4 статьясы | Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр |
| ТР КоАП 2.5 статьясы | Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә тагып йөрү |
| ТР КоАП 2.6 статьясы | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү |
| ТР КоАП 2.7 статьясы | Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу |
| ТР КоАП 2.15 статьяның 2 өлеше | Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу |
| ТР КоАП 2.17 статьясы | Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19)таралуны булдырмауга һәм нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү |
| ТР КоАП 2.19 статьясы | Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү |
| ТР КоАП 2.20 статьясы | Сыекландырылган углеводород газы булган гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен товарларны балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук сыекландырылган углеводород газын сулау юлы белән балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итү |
| ТР КоАП 2.21 статьясы | Режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү |
| ТР КоАП 3.2 | Урамда сәүдә итүне оештыру һәм халыкның күңел ачуына |

| | |
|---|---|
| статьясы | бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу |
| ТР КоАП 3.3 статьясы | Җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозу |
| ТР КоАП 3.4 статьясы | Урамнарны, квартал эчендәге яктыртуны тоту кагыйдәләрен бозу |
| ТР КоАП 3.5 статьясы | Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу |
| ТР КоАП 3.6 статьясы | Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу |
| ТР КоАП 3.8 статьясы | Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу |
| ТР КоАП 3.10 статьясы | Татарстан Республикасы территориясендәге су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен бозу (гражданнарга карата) |
| ТР КоАП 3.11 статьясы | Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәмәү |
| ТР КоАП 3.14 статьясы | Мәдәни-тамаша чараларына барганда җәмәгать тәртибен бозу |
| ТР КоАП 3.15 статьясы | Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү |
| ТР КоАП 3.15.1 статьясы | Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәтләрне көчләп тагу |
| ТР КоАП 3.16 статьясы | Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында)урнаштырган өчен түләмәү |
| ТР КоАП 3.17 статьясы | Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру |
| ТР КоАП 4.4 статьясы | Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу |
| ТР КоАП 5.1 статьясы | Билетсыз йөрү |
| ТР КоАП 5.2 статьясы | Багаж алып бару кагыйдәләрен бозу |
| ТР КоАП 5.6 статьясы | Пассажирга юл бирүдән баш тарту |